ГОРОДСКОЙ СОВЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
ШӘҺӘР СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

25 октябрь, 2023 ел № 27/10

2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына) үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2011 елның 25 августындагы 13/11 номерлы Карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турында Нигезләмә, шәһәр Уставының 28 статьясы нигезендә

Шәһәр Советы

КАРАР бирде:

1) Шәһәр Советының 2022 елның 8 декабрендәге 18/10 номерлы Карары белән расланган (Шәһәр Советының 2023 елның 29 мартындагы 22/11 номерлы Карары редакциясендә) 2023 елга Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкен хосусыйлаштыру Фараз планына (программасына), 6.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә

«6.1. 2023 елда хосусыйлаштыру планлаштырылган муниципаль күчемсез милек:

| № т/б | Объект исеме | Проект билгеләнеше | Капиталь төзелеш объекты мәйданы / озынлыгы | Җир участогы мәйданы | Керем күләме фаразы мең сум | Хосусыйлаштыруның фаразланган вакыты |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | Тәмамланмаган төзелеш объекты, әзерлек дәрәҗәсе 60%, кадастр | Җитештерү | 377 | 781 | 9 900,00 | 2023 елның 4 кварталы |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | номеры 16:52:100402:114, 16:52:100402:100 кадастр номерлы җир участогы | | | | | |
| 2 | Тәмамланмаган төзелеш объекты, әзерлек дәрәҗәсе 40%, кадастр номеры 16:52:060404:522, 16:52:060404:947 кадастр номерлы җир участогы | Эшлекле идарә итү | 107,5 | 1067 | 6528,7 | 2023 елның 4 кварталы |

».

2. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны Шәһәр Советының социаль-икътисадый үсеш мәсьәләләре һәм бюджет буенча даими комиссиясенә, Башкарма комитет Җитәкчесе Ф.Ш. Салаховка йөкләргә.

Шәһәр Хакиме Н.Г. Мәһдиев